# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТУКАЙ ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

21.11.2024 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең
Тукай авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 8 ноябрендәге 8 номерлы карары нигезендә, 2024 елның 21 ноябрендә «2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде.

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тукай авылындагы юлларны кардан чистарту)?»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 9 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 6.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 6 граждан тавыш бирде;

"ЮК" - 0

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнар җыенын узган дип санарга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. Җыен нәтиҗәләрен:

«2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй

авыл җирлегенең Тукай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын азат итеп, кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорау каралды һәм карар кабул ителде.

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тукай авылындагы юлларны кардан чистарту) »- дөрес дип таныргa.

3. Әлеге карарны махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәммәтгалеев
(имза) (имзаның аңлатмасы)